**ЗАКОН**
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

**О внесении изменений в отдельные законодательные акты Республики Татарстан**

Принят
Государственным Советом
Республики Татарстан
21 апреля 2016 года

**Статья 1**

Внести в Семейный кодекс Республики Татарстан (Ведомости Государственного Совета Татарстана, 2009, № 1, № 12 (I часть); 2010, № 12 (II часть); 2011, № 9 (I часть); 2012, № 6 (I часть); 2013, № 5, № 7; 2014, № 4, № 6 (II часть); 2015, № 7 (I часть), № 10 (I часть) следующие изменения:

1) статью 2 изложить в следующей редакции:
«Статья 2. **Отношения, регулируемые семейным законодательством**

Семейное законодательство устанавливает порядок осуществления и защиты семейных прав, условия и порядок вступления в брак, прекращения брака и признания его недействительным, регулирует личные неимущественные и имущественные отношения между членами семьи: супругами, родителями и детьми (усыновителями и усыновленными), а в случаях и в пределах, предусмотренных семейным законодательством, между другими родственниками и иными лицами, определяет порядок выявления детей, оставшихся без попечения родителей, формы и порядок их устройства в семью, а также их временного устройства, в том числе в организацию для детей-сирот и детей, оставшихся без попечения родителей.»;

2) часть 2 статьи 6 дополнить словами «, а также иными способами, предусмотренными законом»;

3) часть 4 статьи 27 изложить в следующей редакции:

«4. Для заключения одним из супругов сделки по распоряжению имуществом, права на которое подлежат государственной регистрации, сделки, для которой законом установлена обязательная нотариальная форма, или сделки, подлежащей обязательной государственной регистрации, необходимо получить нотариально удостоверенное согласие другого супруга.»;

4) статью 29 после слов «может быть признано» дополнить словом «судом»;

5) часть 2 статьи 42 после слов «по заявлению отца ребенка» дополнить словами «(части 3 и 4 статьи 39 настоящего Кодекса)»;

6) часть 2 статьи 53 изложить в следующей редакции:

«2. Несовершеннолетние родители, не состоящие в браке, в случае рождения у них ребенка и при установлении их материнства и (или) отцовства вправе самостоятельно осуществлять родительские права по достижении ими возраста шестнадцати лет. До достижения несовершеннолетними родителями возраста шестнадцати лет их ребенку назначается опекун, который осуществляет его воспитание совместно с несовершеннолетними родителями ребенка. Разногласия, возникающие между опекуном ребенка и несовершеннолетними родителями, разрешаются органом опеки и попечительства.»;

7) в статье 57:

а) в части 5 слова «гражданским процессуальным законодательством» заменить словами «законодательством об административных правонарушениях и законодательством об исполнительном производстве»;

б) в части 6 слова «учреждений социальной защиты населения» заменить словами «организаций социального обслуживания»;

8) в части 4 статьи 58 слова «гражданским процессуальным законодательством» заменить словами «законодательством об административных правонарушениях и законодательством об исполнительном производстве»;

9) в статье 60:

а) в пункте 2 части 1 слова «учреждения социальной защиты населения» заменить словами «организации социального обслуживания»;

б) пункт 6 части 1 изложить в следующей редакции:

«6) совершили умышленное преступление против жизни или здоровья своих детей, другого родителя детей, супруга, в том числе не являющегося родителем детей, либо против жизни или здоровья иного члена семьи.»;

10) статью 65 изложить в следующей редакции:

«Статья 65. **Контакты ребенка с родителем, родительские права которого ограничены судом**

Родителю, родительские права которого ограничены судом, могут быть разрешены контакты с ребенком, если это не оказывает на ребенка вредного влияния. Контакты родителя с ребенком допускаются с согласия органа опеки и попечительства либо с согласия другого родителя, не лишенного родительских прав или не ограниченного в родительских правах, опекуна (попечителя), приемных родителей ребенка или администрации организации, в которой находится ребенок.»;

11) в статье 69 слова «гражданским процессуальным законодательством» заменить словами «законодательством об исполнительном производстве»;

12) в части 2 статьи 74 слова «учреждениях социальной защиты населения» заменить словами «организациях социального обслуживания»;

13) пункт 4 части 1 статьи 80 после слова «нуждающийся» дополнить словом «бывший»;

14) в части 2 статьи 100 слова «гражданским процессуальным законодательством» заменить словами «законодательством об исполнительном производстве»;

15) в пункте 7 части 1 статьи 116 слово «установления» исключить;

16) в части 3 статьи 120 слова «учреждениях социальной защиты населения» заменить словами «организациях социального обслуживания».

**Статья 2**

Внести в статью 9 Закона Республики Татарстан от 29 октября 2009 года № 50-ЗРТ «О профилактике наркомании и токсикомании» (Ведомости Государственного Совета Татарстана, 2009, № 9 – 10; 2010, № 11; 2014, № 7) следующие изменения:

1) в наименовании слово «учреждений» заменить словом «организаций»;

2) в абзаце первом части 2 слово «учреждений» заменить словом «организаций».

**Статья 3**

Пункт 5 части 1 статьи 12 Закона Республики Татарстан от 2 ноября 2012 года № 73-ЗРТ «Об оказании бесплатной юридической помощи гражданам в Республике Татарстан» (Ведомости Государственного Совета Татарстана, 2012,

№ 11 (I часть); 2013, № 11 (I часть); 2014, № 1 – 2, № 12 (II часть) изложить в следующей редакции:

«5) граждане пожилого возраста и инвалиды, проживающие в организациях социального обслуживания, предоставляющих социальные услуги в стационарной форме;».

**Статья 4**

Настоящий Закон вступает в силу через 10 дней после дня его официального опубликования.

Президент
Республики Татарстан

Р.Н. Минниханов

Казань, Кремль
7 мая 2016 года
№ 33-ЗРТ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

**Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2016 елның 21 апрелендә
кабул ителде

**1 статья**

Татарстан Республикасы Гаилә кодексына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2009, № 1, № 12 (I өлеш); 2010, № 12 (II өлеш); 2011, № 9 (I өлеш); 2012, № 6 (I өлеш); 2013, № 5, № 7; 2014, № 4, № 6 (II өлеш); 2015, № 7 (I өлеш), № 10 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 2 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
“2 статья. **Гаилә законнары белән җайга салына торган мөнәсәбәтләр**

Гаилә законнары гаилә хокукларын гамәлгә ашыру һәм яклау тәртибен, никахлашуның, аны туктатуның һәм дөрес түгел дип тануның шартларын һәм тәртибен билгели, гаилә әгъзалары: ир белән хатын, ата-ана һәм балалар (уллыкка алучылар һәм уллыкка алынучылар) арасында, ә гаилә законнарында каралган очракларда һәм чикләрдә башка туганнар һәм бүтән затлар арасында мөлкәти булмаган һәм мөлкәти булган шәхси мөнәсәбәтләрне җайга сала, ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларны ачыклау тәртибен, аларны гаиләгә урнаштыру, шул исәптән ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар өчен оешмаларга вакытлыча урнаштыру рәвешләрен һәм тәртибен билгели.”;

2) 6 статьяның 2 өлешендә “ысуллар” сүзеннән соң “, шулай ук законда каралган башка ысуллар” сүзләрен өстәргә;

3) 27 статьяның 4 өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
“4. Ир белән хатынның берсе хокуклары дәүләт теркәвенә алынырга тиешле мөлкәт белән эш йөртү буенча алыш-бирешне, закон белән мәҗбүри нотариаль рәвеше билгеләнгән алыш-бирешне яисә мәҗбүри дәүләт теркәвенә алынырга

тиешле алыш-бирешне башкару өчен каршы якның нотариаль расланган ризалыгын алырга тиеш.”;

4) 29 статьяда “ачыкланса,” сүзеннән соң “суд тарафыннан” сүзләрен өстәргә;

5) 42 статьяның 2 өлешендә “баланың атасы гаризасы буенча” сүзләреннән соң “(әлеге Кодексның 39 статьясындагы 3 һәм 4 өлешләре)” сүзләрен өстәргә;

6) 53 статьяның 2 өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“2. Никахлашмаган балигъ булмаган ата-ананың баласы туган очракта һәм аларның ана һәм (яисә) ата булулары билгеләнгәндә, алар, уналты яшькә җиткәч, ата-ана хокукларын мөстәкыйль гамәлгә ашырырга хокуклы. Балигъ булмаган ата-ана уналты яшькә җиткәнче, аларның баласына опекун билгеләнә, опекун баланың балигъ булмаган ата-анасы белән бергә аны тәрбияли. Баланың опекуны белән балигъ булмаган ата-ана арасында килеп чыга торган каршылыклар опека һәм попечительлек органы тарафыннан хәл ителә.”;

7) 57 статьяда:

а) 5 өлештә “граждан-процессуаль законнарында” сүзләрен “административ хокук бозулар турындагы законнарда һәм башкару эшчәнлеге хакындагы законнарда” сүзләренә алмаштырырга;

б) 6 өлештә “халыкны социаль яклау учреждениеләреннән” сүзләрен “социаль хезмәт күрсәтү оешмаларыннан” сүзләренә алмаштырырга;

8) 58 статьяның 4 өлешендә “граждан-процессуаль законнарында” сүзләрен “административ хокук бозулар турындагы законнарда һәм башкару эшчәнлеге хакындагы законнарда” сүзләренә алмаштырырга;

9) 60 статьяда:

а) 1 өлешнең 2 пунктында “халыкны социаль яклау учреждениесеннән” сүзләрен “социаль хезмәт күрсәтү оешмасыннан” сүзләренә алмаштырырга;

б) 1 өлешнең 6 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“6) үз балаларының, балаларның атасының йә анасының, иренең йә хатынының, шул исәптән балаларның атасы йә анасы булмаган иренең йә хатынының гомеренә яисә сәламәтлегенә каршы йә гаиләнең башка әгъзасының гомеренә яисә сәламәтлегенә каршы белә торып җинаять кылсалар.”;

10) 65 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“65 статья. **Атасының йә анасының ата-ана хокуклары суд тарафыннан чикләнгән баланың атасы йә анасы белән аралашуы**

Ата-ана хокуклары суд тарафыннан чикләнгән атасына йә анасына бала белән аралашу, әгәр балага зарарлы йогынты ясалмаса, рөхсәт ителергә мөмкин.

Атасының йә анасының бала белән аралашуы опека һәм попечительлек органы ризалыгы белән йә ата-ана хокукларыннан мәхрүм ителмәгән яисә ата-ана хокуклары чикләнмәгән атасы йә анасы, опекун (попечитель), баланы тәрбиягә алган ата-ана яисә бала тора торган оешма администрациясе ризалыгы белән рөхсәт ителә.";

11) 69 статьяда "граждан-процессуаль законнарында" сүзләрен "башкару эшчәнлеге турындагы законнарда" сүзләренә алмаштырырга;

12) 74 статьяның 2 өлешендә "халыкны социаль яклау учреждениеләрендәге" сүзләрен "социаль хезмәт күрсәтү оешмаларындагы" сүзләренә алмаштырырга;

13) 80 статьяның 1 өлешендәге 4 пунктында "ярдәмгә мохтаҗ" сүзләреннән соң "элеккеге" сүзен өстәргә;

14) 100 статьяның 2 өлешендә "граждан-процессуаль законнарында" сүзләрен "башкару эшчәнлеге турындагы законнарда" сүзләренә алмаштырырга;

15) 116 статьяның 1 өлешендәге 7 пунктында "уллыкка алуны билгеләү" сүзләрен "уллыкка алу" сүзләренә алмаштырырга;

16) 120 статьяның 3 өлешендә "халыкны социаль яклау учреждениеләрендә" сүзләрен "социаль хезмәт күрсәтү оешмаларында" сүзләренә алмаштырырга.

**2 статья**

"Наркоманияне һәм токсикоманияне профилактикалау турында" 2009 елның 29 октябрендәге 50-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 9 статьясына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2009, № 9 – 10; 2010, № 11; 2014, № 7) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) исемендә "учреждениеләренең" сүзен "оешмаларының" сүзенә алмаштырырга;

2) 2 өлешнең беренче абзацында "учреждениеләре" сүзен "оешмалары" сүзенә алмаштырырга.

**3 статья**

"Татарстан Республикасында гражданнарга түләүсез юридик ярдәм күрсәтү турында" 2012 елның 2 ноябрендәге 73-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 12 статьясындагы 1 өлешенең 5 пунктын (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2012, № 11 (I өлеш); 2013, № 11 (I өлеш); 2014, № 1 – 2, № 12 (II өлеш) түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“5) стационар рәвештә социаль хезмәт күрсәтүче социаль хезмәт күрсәтү оешмаларында яшәүче олы яшьтәге гражданнар һәм инвалидлар;”.

**4 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты

Р.Н. Миңнеханов

Казан,Кремль
2016 елның 7 мае
№ 33-ТРЗ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ * АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН *
ГОМУМИ БУЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ